**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турында**

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү максатларында, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты төзү турындагы тәкъдиме белән килешергә.

2. Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтләр бирелгән, шулай ук федераль законнар нигезендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләрне (алга таба – Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләр) тормышка ашыручы махсус компетенцияле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты арасында мәдәни мирас объектларын саклау буенча вәкаләтләрне бүлешүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турындагы нигезләмәне эшләргә һәм расларга, шулай ук аның структурасын раслауга кертергә;

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары санын билгеләү турында тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты хезмәткәрләренең чик санын расларга, шулай ук аның эшчәнлеген финанслауга ассигнованиеләр күләмен, әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә вәкаләтләр бүлешүне исәпкә алып, «2018 елга һәм 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акча кысаларында билгеләргә;

бүлеп бирелгән субвенцияләрне тоту турында кварталлык хисапның, Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләр мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар нөсхәләренең, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясе тапшырган вәкаләтләрнең тулысынча һәм сыйфатлы үтәлешенә контроль һәм күзәтчелек өчен кирәкле булган башка документларның һәм мәгълүматның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан мәдәни мирас объектларын саклап калу, аларны файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтләр тапшырылган федераль башкарма хакимият органына вакытында бирелүен тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аның үтәлешен тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-890 номерлы, 2017 елның 26 декабрендәге ПУ-1168 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге ПУ-426 номерлы һәм 2018 елның 22 июнендәге ПУ-454 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына, IV кисәккә «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2008 елның 17 маендагы ПУ-228 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 28 июнь
№ ПУ-462